МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.12.2019 г.Казань № 1125

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 21 гыйнварендә 6480 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2019-2022 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның үз ирекләре белән Татарстан Республикасына күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасында катнашуга кандидатураларны килештергәндә кулланыла торган мөһим бәяләү критерияләрен раслау турында» 2019 елның 23 маендагы 398 номерлы боерыгы кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2022 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның үз ирекләре белән Татарстан Республикасына күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» 2012 елның 31 декабрендәге 1199 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында» 2019 елның 26 апрелендәге 344 номерлы карары белән расланган «2019-2022 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның үз ирекләре белән Татарстан Республикасына күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2019-2022 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның

үз irekләре белән Татарстан Республикасына күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасында катнашуга кандидатураларны килештергәндә кулланыла торган мөһим бәяләү критерияләрен раслау турында» 2019 елның 23 маендагы 398 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 13 ноябрендәге 995 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кушымтасына, аны яңа редакциядә (кушымта итеп бирелә) бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 23 маендагы 398 номерлы боерыгы белән расланды (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 23.12.2019 ел. 1125 номерлы боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2022 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның үз ирекләре белән Татарстан Республикасына күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» 2012 елның 31 декабрендәге 1199 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында» 2019 елның 26 апрелендәге 344 номерлы карары белән расланган «2019-2022 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның үз ирекләре белән Татарстан Республикасына күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасында катнашу өчен кадидатураларны килештергәндә кулланыла торган мөһим бәяләү критерияләре

| «2019-2022 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның үз ирекләре белән Татарстан Республикасына күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасында катнашуга кандидатураларны килештергәндә кулланыла торган бәяләү критерияләре[1] | Бәяләү критерияләренең мөһимлеге |
|---|---|
| 1. Яше | Максимум 15 |
| • 18-29 яшь | 15 |
| • 30-34 яшь | 13 |
| • 35-39 яшь | 11 |
| • 40-44 яшь | 9 |
| • 45 яшькә кадәр һәм эшкә сәләтле булган яшькә кадәр | 7 |
| • хезмәткә яраклы яшьтән өлкәнрәкләр | 5 |
| 2. Мәгариф | Максимум 12 |
| • Гыйльми дәрәҗәсе | 12 |
| • Мәгариф учреждениеләрендә алынган югары белеме:<br>• | |
| - Россия Федерациясендә (СССР) | 10 |

[1] Алга таба – Бәяләү критерияләре

| | |
|---|---|
| - башка дәүләтләрдә | 8 |
| • Урта һөнәри белем, һөнәри белем бирү | 7 |
| 3. Эш стажы | Максимум 10 |
| • 5 елдан артык | 10 |
| • 3-5 ел | 8 |
| • 1-3 ел | 5 |
| • Бер елдан азрак | 2 |
| 4. Хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру (гариза бирү вакытына) | Максимум 15 |
| • актуаль фәнни һәм технологик эшләнмәләр өлкәсендә | 15 |
| • мәгариф, сәламәтлек саклау, авыл хуҗалыгы, спорт, мәгълүмат-коммуникация технологияләре, машина төзелеше өлкәләрендә. | 12 |
| • башка өлкәләрдә | 10 |
| 5. Татарстан Республикасы икътисады үсешенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган, ел саен Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан раслана торган, соралучы һөнәрләр һәм белгечлекләр исемлегенә туры килгән белем буенча һөнәргә (белгечлеккә) ия булу | 10 |
| 6. Иренең (хатынының) һөнәри белеме булу | 4 |
| 7. Балигъ булмаганнарны да кертеп, кандидат белән бергә күченә торган балаларның булуы | 4 |
| 8. Россия Федерациясе һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында белем ала торган студентлар (алынган белемен исәпкә алмыйча) | 30 |